**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23нчейортЛаешш.
422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

28 сентябрь 2022 2299 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы, Лаеш районы,
Лаеш шәһәре, Совхозная ур., 101 адресы
буенча урнашканкадастр номеры 16:24:170202:88:
булган җир кишәрлеге территориясен
межалау проектын әзерләү турында**

Территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары нигезендә капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Лаеш шәһәре, Совхозная ур., 101 адресы буенча урнашканкадастр номеры 16:24:170202:88: булган җир кишәрлеге территориясен межалау проектын әзерләүгә керешергә.

2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43 статьясы нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.

3. Проектны әзерләү срогын, гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыруны исәпкә алып, 2023 елның апреленә кадәр билгеләргә.

4. Физик һәм юридик затларга әлеге карар бастырылганнан соң ундүрт көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне межанлау проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы

Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**